ЧИКЛӘНГӘНЛЕК

Белемнәребез шактый сай булган бер юнәлеш бар...

> 2

КҮЗГӘ КЕБЕК

Икътисадый үсеш алган төбәкнең юллары да тизек була

> 2

ТАТАР ТАШЫ

Әлегә Германиядәге татар зираты мактанырлык хәлдә түгел

> 3



ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фотоертекләр – бирелдә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 61 (29028) | Шимбә | 29 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

АГАЧЛАР – ХӘТЕР САГЫНДА

Яшәеш

Агачлар табигатьнең генә түгел, кешенең дә саулыгын саклый. Ләкин алар үзләре дә тәрбиягә мохтаҗ. Бүген Татарстанда «Хәтер бакчасы» халыкара акциясе узачак. Әлеге чара Бөек Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итү кысасында үтә. Аның максаты – Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган 27 млн ватандашыбыз истәлегенә 27 млн данә агач утырту.

– «Хәтер бакчасы» акциясе республикада дүртенче тапкыр уздырыла, – ди Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров. – Теләге булганнарны әлеге чарага кушылырга чакырабыз. Тарихи мәгълүматлар буенча, 378 мең татарстанлы якыннары янына әйләнеп кайта алмаган.

Узган ел әлеге акция барышында 1,2 млн үсенте утыртылган булган. Быел да шул чама агач утыртырга ниятлиләр.

Быел әлеге чара тагын да тирәнрәк мәгънәгә ия. Мөслим халкы әнә шул фикердә тора. Районда агач утырту акциясе апрельдә үк башланып киткән инде. Җиңү паркы һәм «Яшьлек» комплексындагы 5 гектар җиргә 12 мең төп агач утыртылган.

– Без бу эшләрне хәрби операциядән ялга кайткан райондашларыбыз, Әфган һәм Чечня сугышларында катнашкан ветераннарыбыз белән бергә башкардык, – диде Мөслим районының аппарат советы җитәкчесе Ренат Гарипов. – Шулай итеп, алар үзләренә әлеге агачларны карап торырга күпмедер дәрәҗәдә йөкләмә дә алдылар. Хәрби операциядә катнашучы егетләребезнең кәефе көр. Киткәндә күзләрендә билгесезлек, шом, курку булса, хәзер алар – үз-үзләренә ышанган ир-атлар. Күпчелеге: «Җиңү – безнең якта», – ди.

Хәзер исә Мәллтамак авылындагы һәвәскәр авылдашлар булдырган парк яшеллеккә күмеләчәк.

– Бу чараның максаты агач утырту гына түгел. Халык белән аралашабыз, аңлатабыз, хәзрәтләребезнең хәер-фатихаларын алабыз, укучыларга патриотик тәрбия турында да онытмыйбыз. Агачлар яу кырында башын салган, сугышта катнашкан әби-бабайларыбыз истәлеге булып торачак. Алар барысы да – безнең өчен герой. Гомумән, районда торак пунктларда агач утыртуга зур игътибар бирәбез, аларны ел саен арттырабыз. Узган елларда агач үсентеләрен Мөслим тирәли утыртып чыккан идек. Анда да өлкәннәрнең теләкләрен искә алып, кайсыдыр агачларны билгеле бер кешеләргә атап утырттык, – диде Ренат Гарипов.

«Нурлат урманчылыгы» идарәсенең Мамык участогы урман караучысы Наилә Сафиуллина – 35 елга якын гомерен урманны саклауга багышлаган белгеч. Аны әле республиканың бердәнбер хатын-кыз урманчысы буларак та беләләр.

– Урман – минем икенче йортым, чөнки аның белән бөтен тормышым бәйләнгән. Аның язмышы өчен бик борчылам. Мин Бутаиха урман бистәсендә туып-үстем, әтиәнием дә урман хуҗалыгында эшләде. Табигатьнең әлеге бай бүләген саклау өчен сайланган һөнәремдә әнә шуның да зур тәэсире бар. Безнең төп эшебез – урманнарны корткычлардан, законсыз рәвештә кисүчеләрдән саклау һәм карап тоту. Янгыннардан да, зыян салучы кешеләрдән дә сакларга туры килә. Хәзерге вакытта да эшебез бик күп. Көн-төн кизү торабыз. Урманнар өчен иң куркыныч чор башланды, – ди ул.

Наилә Сафиуллина әйтүенчә, 2010 елгы корылыктан соң һәлак булган агачларны торгызуга шактый көч салырга туры килә.

– Ул елда агачлар бик күп һәлак булды. Без әле дә булса аларны тернәкләндерү белән шөгыльләнәбез. Корыганнарын урманнан чыгарып, яңа үсентеләр утырттык. Кайдадыр урман үзен үзе коткара. Бер гектар җиргә 481 данә агач утыртабыз. Юл буйларына утырткан агачларны да дүрт ел рәттән тулыландырып, мәйданнарны яшелләндерәбез. Үзем чыршыны матурлыгы өчен бик яратам, – ди ул. – Урманның җаны бар. Ул да кешеләр кебек үк сулый, яши, һәлак була. Агачларның очлары корыса яки сынса, гомерләре өзелә. Авырулары да чыгып тора. Узган ел, мәсәлән, күп агачларны ефәк күбәләге харап иткән иде. Быел менә шуңа каршы чаралар уздырабыз. Урман, агач утырту буенча акцияләр кирәк һәм аларның әһәмияте зур. Ул бит – хәтер. Бердән, һәр агач хәтер сакласа, икенчедән, табигатькә файда китерә.

Нурлат урманнарында куяннар, төлкеләр, кыр кәҗәләре, пошилар, кабан дуңгызлары, бүреләр һәм хәтта аюлар да бар. Ерткыч җанварның үзе белән күзгә-күз очрашырга туры килмәсә дә, өнен күргәне булган Наилә ханымның.

– Урман хуҗаларының саннары елдан-ел үзгәреп тора, – ди ул. – Аюлар безнең урманнарга күрше төбәкләрдәге янгыннардан соң күчте. Кабан дуңгызлары, кыр кәҗәләре, пошилар арту күзәтелә.

Сүз уңаеннан, быел Урман хуҗалыгы министрлыгы 3614 гектар урманны кабат торгызырга планлаштыра. Шулардан 1413 гектарда урман культуралары утыртырга, 2092 гектарда табигый урманнарны катнаш торгызырга һәм 105 гектарда урманны арттырырга ниятлиләр. Шулай итеп, быел урманнарны арттыру буенча планлаштырылган эшләр барлыгы 5322 гектарны тәшкил итәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН УРМАННАРЫ

(Барлык территориянең урман биләгән өлеше, процентларда)

Татарстан буенча	17,5	Югары Ослан	18,4	Түбән Кама	26,8
Әгерҗе	23,8	Биектау	18,7	Яңа Чишмә	10,6
Азнакай	18,7	Чүпрәле	2,9	Нурлат	41,0
Аксубай	21,9	Алабуга	13,7	Питрәч	12,4
Актаныш	7,0	Зәй	28,5	Балык Бистәсе	25,3
Алексеевск	11,3	Яшел Үзән	25,7	Саба	24,8
Әлки	21,0	Кайбыч	16,9	Сарман	5,9
Әлмәт	27,9	Кама Тамагы	8,3	Спас	9,4
Апас	8,3	Кукмара	20,4	Тәтеш	16,1
Арча	12,2	Лаеш	15,8	Теләче	15,1
Әтнә	4,0	Лениногорск	26,6	Тукай	13,0
Баулы	18,1	Мамадыш	28,4	Чирмешән	25,0
Балтач	10,7	Менделеевск	5,9	Чистай	7,4
Бөгелмә	19,7	Минзәлә	11,1	Ютазы	10,9
Буа	6,5	Мөслим	18,6	Казан	11,7

(Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2023 ел)

300 көн калды

Мәгълүм булганча, 2024 елда Казанда «Киләчәк уеннары» ярышы узачак. Шимбә әлеге чарага ничә көн калганны күрсәтеп баручы стеланы эшләтеп җибәрәчәкләр. Сүз уңаеннан, 29 апрельдә Уеннарга кадәр төгәл 300 көн калачак. Тантана ике шәһәрне – Мәскәү һәм Казанны берләштерәчәк. Татарстан башкаласында стеланы тантаналы төстә Рәис Рөстәм Миңнеханов, ә Мәскәүдә Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко ачачак.

Тантананы алып барырга виртуаль алып баручы ярдәм итәчәк, аның образы һәм тавышы ясалма интеллект ярдәмендә барлыкка китерелгән.

Бу чара кысасында Илкүләм фиджитал спорт федерациясен тәкъдим итүгә, «Киләчәк уеннары» талисманына тавыш бирүгә әзерлек тә старт алачак.

Бурычлы мөлкәтен күрмәс

Ел башыннан бирле республикада 1059 кеше милеккә салым буенча җыелган бурычын түләмәгән өчен мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. Республика суд приставлары идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, хуҗаларыннан алынган мөлкәтнең гомуми бәясе 350 миллион сум тәшкил иткән.

Исегезгә төшерәбез: суд приставлары салым түләмәүчеләрнең мөлкәтенә арест салырга яисә аны тартып алырга мөмкин. Быел алар бурычлыларны барлыгы 105 миллион сумлык 255 машина һәм 218 миллион сумлык 181 күчемсез милектән коры калдырган инде.

Суд приставлары идарәсе тагын бер кат бурычны вакытында түләргә кирәклеген искәртә. «Банк данных исполнительных производств» сервисы аша үзеңнең бурычлымы-түгелме икәнлегеңне белергә мөмкин.

Психолог тыңлый

1 июльдән сырхауханәләрдә психологларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин булачак. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко әйтүенчә, хәзер дәвалау оешмаларында медицина психологлары яңача эшләячәк. ТАСС хәбәренә караганда, махсус хәрби операциядә катнашучылар да белгечләргә күренә алачак.

Гыйнварда хәбәр ителгәнчә, илдә психолог һәм психотерапевтларга мөрәҗәгать итүчеләр саны бер ел эчендә 7 тапкыр арткан. Бигрәк тә узган елның сентябрь һәм октябрь айларында мондыйлар бик күп булган. Киңәш сораучыларның 82 проценты – хатын-кызлар. 53 проценты – 26–35 яшьлекләр, 17 проценты – 18дән 25 яшькә кадәрге яшьләр.

Психологларга башлыча депрессия, гаиләдәге, эштәге проблемалар буенча киләләр.

Монысы да йогышлы

Татарстанда кызамык йоктыруның 46 очрагы теркәлгән. Чирләүчеләрнең 20се – балалар. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары әйтүенчә, республикада 12047 кешенең чир ияртүчеләр белән элемтәдә торуы ачыкланган. Шуларның 1409ына прививка ясатырга кирәк булган. 82 проценты вакцинация узган да инде.

Бездә 5 февральдән кызамык белән чирләүчеләр теркәлә башлаган. Чир йоктыручыларның күпчелеге (80%) – Таҗикстаннан килүчеләр. Мисыр, Мәскәү, Новосибирск һәм Бурятиядән дә чир ияртеп кайту очраклары бар.

Сүз уңаеннан, Татарстанга кызамыкка каршы вакцина кайтарылган. Ул республиканың барлык медицина оешмаларына диярлек бүлеп бирелгән.

Исегезгә төшерәбез: февраль һәм март айларында республикада кызамык йоктыруның 13 очрагы ачыкланган. Сырхауларның барысы да чирне читтән ияртеп кайткан.

Горурлык

Нәсел юлы

КАЗАНДА ДАНЛЫКЛЫ ХЕЗМӘТ ДИНАСТИЯЛӘРЕН ЗУРЛАДЫЛАР

13 язмыш, 13 тарих, гомер буе үз һөнәренә тугры булып яшәгән 13 нәсел... Кичә Казан Кремлендә республиканың төрле тармакларын үстерү, күтәрүгә саллы өлеш керткән хезмәт династияләрен зурладылар. Араларында укытучы да, урманчы, очкыч төзүче, нефтьче, журналист та – барлык һөнәр ияләре дә бар.

Үз һөнәре, нәселе турында сөйли башлауга, һәркайсының йөзенә нур йөгерә, күзләрендә үзгә бер горурлык хисе чагыла. Үз һөнәренең тәмен, нәселенең кадерен белгән ихлас кешеләр алар.

Арча районында яшәүче Гөлназ һәм Руслан Гыйниятуллиннар – данлыклы укытучылар нәселенең өченче буыны. Аларның әти-әниләре дә, әби-бабайлары да гомер буе балаларга белем биргән. Барысына бергә 1000 еллык эш стажы җыела. Барың бер казанда кайнагач бик рәхәт, ди алар.

– Укытучылар гаиләсендә үскәч, башка юлны сайлыйсы дип башка да килмәде. Тормыш иптәшем Гөлназ да – укытучылар нәселенең дәвамчысы. Әти-әниләребез безгә бер үк вакытта остаз да булды. Хәзер инде дүртенче буын укытучыларыбыз да безнең эзгә басып килә. Укытучы киләчәгебез булган балаларга белем бирә. Димәк, илебез киләчәге дә – безнең кулда, дип әйтергә була, – ди Арчаның Укучылар сарае директоры Руслан Гыйниятуллин.

Аның әтисе, бөтен гомерен мәгариф тармагына багышлаган тәҗрибәле укытучы Наил Гыйниятуллин да үз һөнәре турында горурлык хисе белән сөйли. Яңа Кенәр мәктәбендә озак еллар математика укытканнан соң, Арчаның төрле мәктәпләрендә директор вазыйфасын башкарган ул.

– Бу һөнәрне сайлаганга үкенгән вакытларым булмады. Тормышны яңадан башлыйсы булса, кабат шул юлдан китәр идем. Үз эшемне бик яратып башкардым. Дөрес, хәзерге мәктәп без укыган, укыткан чор белән чагыштырганда бик нык аерыла. Хәзер балаларның аң дәрәҗәсе бик югары. Бу үз чиратында укытучыны да әзерлеген һәрвакыт күтәреп торырга этәрә. Соңгы елларда укытучының абруе үсә бару да сөендерә, – ди ул.

Алабуга урман хуҗалыгы җитәкчесе Миңнегаян Мөхәммәтҗанов, уенын-чынын бергә кушып, эшебез дә, гаиләбез дә – урман безнең, ди. Кырык елдан артык гомерен шушы эшкә багышлаган урманчының янында басып торган тормыш иптәше Рамилә ханым да югалып калмады. «Урман кешесен сайлагач, мин дә урманга кереп киттем инде. Шушында хисапчы булып эшләдем», – дип шаяртты ул. Миңнегаян абыйның әтисе Таһир белән әнисе Газизәне дә урман кавыштырган. Бүген җиде балаларының өчесе урман хуҗалыгында эшли. Оныклары да шул юлдан киткән.

– Әти бездә кечкенәдән урманга мәхәббәт тәрбияләде. Гел үзе белән иярте иде. Урман табигате, матурлыгы белән күңелгә якын, – ди Миңнегаян Мөхәммәтҗанов.

Казанда яшәүче Назаровлар да гомерлек һөнәрләре өчен бабаларына рәхмәтле. Алар барысы да С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводында эшли. Бабалары заманында заводтан ерак түгел урында гына йорт салып чыккан. Бер үк вакытта шушы заводта да эшләгән. Шуннан бирле Назаровлар заводка тузан төшерми. Олысы да, кечесе дә гомерлек юлдашы итеп авиация тармагын сайлаган. Алар нәселенең бу тармактагы гомуми эш стажы 1 мең елдан арта.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Рифкать МИҢНЕХАНОВ, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе:

Яшьтән сәламәт тормыш алып барган кеше бөтенләй башкача картая. Һәм моны статистика да раслый. Яшьләрне спортка тарту өчен, аның уңай нәтиҗәләре турында күбрәк сөйләргә, күбрәк күрсәтергә кирәк. Спорт әле ул дисциплина да тәрбияли.

(«Татарстан» журналына биргән интервьюдан)

МАЙ ЯЛЛАРЫН НИЧЕК УЗДЫРЫРГА ҖЫЕНАСЫЗ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләргә шул сорауны биргән.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Чиксезлек һәм без

«Күктә ниләр булмас дисең – очсыз-кырыйсыз күк бит ул!» Фәкыйрегезгә генә түгел, күпләргә бик тә кызыклы булган, тик, ни кызганыч, ул әлкәдәге белемнәребез шактый сай калып килгән бер юнәлеш бар. Ул да булса меңнәрчә йолдызларны, галактикаларны үзенә сыйдырган коточкыч зур киңлек – галәм һәм аның тәэзелеше турындагы фән – астрономия. Галәм масштабыннан караганда, үзебезнең ни дәрәҗәдә вак тереклек ияләре, вак мәнфәгатьләр, вак эшләр майтаручылар булуыбыз хакында сөйләшү теләге нәкъ менә шуннан, Халыкара астрономия көне сәбәпле туды. Тукай әйткән шул «очсыз-кырыйсызлык» пыялага бераз гына кагылып китәсе килгән иде.

Ул әлкәгә керүгә, берсеннән-берсе катлаулы сораулар туа. Җир шары дип аталган сфера өслегендә тереклек итүче, үзен зиһенле санаган җан иясенең яшәешеннән «галәм» дигән ул чиксезлеккә нинди дә булса кирәклек бармы? Галәм күзлегеннән караганда без – кемнәр? Кая барабыз? «Homo sapiens» – эволюция җимешеме, әллә аның ялгышлыгы? Бәлки кемнәрдер безне бары үз кирәклеге өчен генә асрап, үрчетеп ятадыр?..

Башта алда әйтелгән чиксезлекне, аңларга авыр булган зурлыкларны күз алдына китерергә тырышыйк. Һәммәбез дә, көн бөртегенең кечкенәлеген чамалаган кебек, Сахара дигән чүлнең дә җирдә иң зур комлык икәнен беләбез. Шул җәһәттән, әгәр дә: «Без яшәгән планета – галәм дип аталган алагаем чүлдә кечкенә бер ком бөртеге», – дисәк, ихтимал, ялгышырбыз. Кояшны, безнең кояш системасын ком бөртегенә тиңләсәк тә бик үк дөрес булмас. Әмма менә аркылысы 100 мең яктылык елы (яктылык нурының 100 мең елда нинди ара үткәнен күз алдына китерү дә авыр) саналган, Киек каз юлы дип аталган галактикабыз галәм чиксезлегендә шундыйрак үлчәмдә дип белдерсәк, аны ком бөртегенә чыгарсак, хакыйкатькә күпмедер якын килербез кебек. Галәм – гади кешене әйткән дә юк, галимнәр дә шактый аз белгән, адәми зат беркайчан да төшенеп бетә алмаячак биниһая зур дөнья ул. Ул – Бөек билгесезлек. Ул – чиксезлек.

Сүз уңаеннан шунысын да билгелик: дөнья дигәннән, аның әле тагын безне гаҗәпләтерлек, чикләнгән гыйлемдә тоткан кечесе дә бар. Мәсәлән, шул ук вируслар дөньясы. Кем, кайсы галим бүген кистереп: «Вируслар – соңгы чик, аларның үз микроорганизмнары, үз вируслары юк», – дип әйтә ала? Беркем дә әйтә алмый. Бу факт тагын да бер нәрсәне – без яшәгән чынбарлыкның масштаб күләре буенча алгарда да чикләре булмаганлыкны аңлата. «Зур», «кечкенә» дигән бәяләр барысы да чагыштырмача.

Сүз зур дөнья, бөек чиксезлек – галәм хакында иде бит әле. Кеше затының, бер караганда, анда эше дә юк кебек. Галәм хакындагы белем, әйткәнебезчә, минимальле. Җирдәге кеч, гайрәт, ресурслар күбрәк башка якка юнәлтелгән. Күз алдына китерик: кемдер – утә кодрәтле җан һәм гакыл иясе, Кояш системасын микроскоп пыяласына куя да карый, өйрәнә башлый. Күрә: тугыз планетаның берсендә ниндидер вак биологик тәр яшәп, үрчеп ята. Өйрәнә торгач, ул шуны да күрә: биологик затларның ике аякта йөри торганнары шәһәрләр төзегәннәр, транспорт чаралары булдырып, аларны үз хаҗәтләрендә файдаланырга өйрәнгәннәр. Хәтта очкычлар ясый, аларда оча да беләләр. Тик чү, монысы нәрсә? Алар үзләре төзегән шәһәрләрне үзләре үк җимерәләр түгелме? Ул гынамы, үзләре үк тудырган төрледән-төрле җайланмалар ярдәмендә, үз ишләрен юк итәргә дә һәвәсләнгән ич болар. Үзара тукмашмаганда да яшәгән тиралекләрен туктаусыз пычратырга хирысланганнар... Кыек юлга баскан нинди дивана, нинди сансыз цивилизация соң бу? Боларның яшәвендә, җан асравында нинди мәгънә? Бәлки «дихлофос» сибәсе дә барысын да тончыктырасыдыр? Тик ул чакта җан ияләренең дүрт аякта йөргән зыянсызлары – фауна, мәңгәргән тәр үсемлек – флора да юкка чыгачак. Ярар, әлегә исән торсыннар. Ихтимал, болай кылансалар, озак яши алмаслар – уз башларына ашкынулары, мордарлыкка юл тотканнары күренеп тора... Югары акыл иясе, микроскобын читкәрәк куеп, шулайрак фикер йөртер иде кебек.

Югары акыл, аның ияләре, дигәннән. Нәкъ шулар Җир дигән резервациягә кеше затын урнаштырып, биредә безне үрчетә һәм ниндидер үзләренә кирәкле тәҗрибәләр алып бара, дигән фараз кайбер галимнәр арасында электән яши. Имеш, ул артык акыллылар, адәми заттан без белмәгән ниндидер энергетиканы да алып, ягъни безләрне «савып» та тора. Булырга мөмкин. Файда китермәгәч, без аларга ни пычагыма. Шуны да искәртәсе килә: акыл, дибез икән, ул кешедәге кебек биологик кимәлдә генә булырга тиеш димәгән. Ник әле ул плазма рәвешендә, яисә электромагнит күре, дулкыннар формасында була алмый? Ала. Материянең, шул исәптән аңның да форма-рәвешләре, без аны күз алдына бик китерә алмаслык да, төрледән-төрле булырга мөмкин бит. Кеше затыкын таныл белү мөмкинлеге бик чикле, без андый югары аң, андый материяләр хакында башыбызга да китермибез. Кая ул китерү, ВЦИОМ үткәргән сораштыруларда, югары технологияләр, дип шапырынган заманда да халыкның 35 процентының, Урта гасырлардагыча фикер йөртеп, Кояш Җир тирәли әйләнеп йөри, дип санавын бер язган идек инде. Менә ул – безләрдәге аң-гыйлем дәрәҗәсе!

Үзебездәге шундый гыйлем белән без әле тагын: «Галактикалар күп икән, кайдадыр тагын акыллы технологик цивилизация яшәргә, ерак йолдызлыклардан очып килеп, безнең белән элемтәгә керергә тиеш», – дип уйлыйбыз. Тик менә галактикалар арасын ике аяклы арасы кебек кенә күргәннәргә бездәге «акыл» белән без нигә? Карап торуга әнә бал кортлары да – цивилизация. Бер караганда, акылсыз да түгел кебек үзләре – эш, вазыйфалар буленгән, кайсы юнаешттә, нинди ераклыкта нектар барын да бер-берсенә җиткерә беләләр хәтта. Тик кеше алар белән ниндидер элемтәгә керү, контакт булдыру турында уйламый бит. Без кортлардан файдаланабыз гына. Акыл ягыннан бездән өстен цивилизациягә без ни хаҗәтемә? Ә зиһенгә ерак китә алмаганнар, ихтимал, нәкъ безнең кебек, кайдадыр узара тукмашып ятадыр. Кая аларга бер галактикадан икенчесенә барып җитү. Башка «важный» эшләр булганда...

Чиксезлек һәм чикләнгән аң. Чикләнгән, җитлекмәгән акыл ул дөньяны, шул исәптән галәмне танып-белүдәге житешсезлек кенә түгел, шул ук үзара ызгышып ятулар, сансызлык, башкасы да. Адәми заттагы геномны тәзәтми торып, без ул затсызлыклардан котыла алмаячакбыз. Кем аны тәзәтергә тиеш – «хуҗалар»мы, әллә үзебезме? Сорау әлегә ачык кала.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЮЛНЫҢ ОЛЫСЫ-КЕЧЕСЕ ЮК

Татарстанда ел саен 700 чакрымнан да ким булмаган озынлыкта авыл юллары салына һәм төзекләндерелә. Зур юлларны әйтеп тә торасы юк. Республикада әлеге тармак – өстенлекле юнәлешләрнең берсе, диделәр «Казан Экспо»да узган чарада.

Башкалада Росавтодорның «Россия Федерациясе субъектлары территориясендә юл эшчәнлеген тормышка ашыруда нәтиҗәле алымнар» фәнни-гамәли конференциясе кысасында Төбәкләр үсеше буенча Хөкүмәт комиссиясе президиумы (штабы) утырышы узды. Чарада Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Юл федераль агентлыгы җитәкчесе Роман Новиков катнашты.

Рөстәм Миңнеханов республиканың юл хуҗалыгы инфраструктурасы турында сөйләде.

– Россия Хөкүмәте ярдәме белән республикада зур масштаблы федераль проектлар тормышка ашырыла. М12, Чаллы һәм Түбән Камаңы урап узучы «Казан – Екатеринбург» автомагистрале тәзелешләре, М7 һәм М5 транспорт коридорларын тоташтыру максатыннан, дәүләти-хосусый хезмәттәшлек механизмын кулланып, «Алексеевск – Әлмәт» юлын салалар. Әлеге проектларны тормышка ашыру республиканы Идел буеның башка төбәкләре, Үзәк Россия һәм Урал белән тоташтырачак яңа логистик маршрутлар булдырырга ярдәм итәчәк. Шулай ук, бүгенге кебек санкция шартларында да төбәкара элемтәләрне үстерергә булышачак. Масштабы проектларны тормышка ашырганнан соң, тәзелеш барышында файдаланылган төбәк һәм җирле юлларны тәртипкә китерү дә мөһим, – диде Рәис.

Татарстанда автомобиль юлларының төп челтәре озынлыгы 2,6 мең чакрымнан артып китә.

– Былтыр республикада сәнәгать җитештерүе күләме 4,6 триллион сумнан да күбрәк тәшкил итте, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Шуңа күрә безнең өчен юлларны, беренче чиратта, төп челтәрләрне үстерү өстенлекле әһәмияткә ия.

2024 ел ахырына кадәр республиканың төп челтәренә кергән юлларның 85 процентын норматив хәлгә китерү бурычы тора. Бу җәһәттән, Россия Президенты Владимир Путин йөкләмәсе нигезендә Татарстанда юл эшләренең биш еллык программасы тәзелде. Төп челтәргә керүче юлларда 130 чакрымнан артык юлны төзекләндерү һәм аларның йөк күтәрүчәнлеген 11,5 тоннага кадәр җиткерү күздә тотыла.

Федераль дәрәҗәдәге төп челтәрләрне алга таба үстерү өчен, төбәкләрнең төп челтәрләрен формалаштырырга да тәкъдим итте Рөстәм Миңнеханов.

– Аның нигезендә район үзәкләрен һәм субъект башкаласын тоташтыручы трассалар, эре сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм туризм объектларына юллар, шулай ук күрше төбәкләр арасындагы магистральләр булырга тиеш, – диде Рәис.

Марат Хөснуллин билгеләп үткәнчә, илдә төбәк юлларының 50 проценты норматив хәлгә китерелгән. 500 мең чакрым чамасы юл бу! Шул ук вакытта 18 төбәк әлеге күрсәткечкә ирешмәгән әле.

– Татарстан бу санны 80 процентка җиткерде. Безгә муниципаль юллар турында да онытырга ярамый. Бәлки, бирәдә хәрәкәт ул дәрәҗәдә үк тыгыз түгелдер, әмма алар һәр кешегә, һәр торак пунктка кагыла. Мондый юллар бездә 1 миллион чакрымнан да артык, – диде Марат Хөснуллин.

Утырыш ахырында ул 2022 елда «Сыйфатлы имин юллар» илкүләм проектын тормышка ашыруда уңышка ирешкән төбәкләрне билгеләп үтте. Татарстан – алдынгыларның берсе.

Кунак көткәндә

Дөньяның 65 иленнән һәм Россиянең 30дан артык төбәгеннән вәкилләр, 150дән артык эшлекле очрашу. Татарстан башкаласында 18–20 майда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»га әзерләнәләр.

«Казан Экспо»да халыкара икътисадый форумга әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты утырышы узды. Аны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары, оештыру комитеты рәисе Марат Хөснуллин үткәрде. Чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Марат Хөснуллин искәртүенчә, ислам дөньясы илләре белән хезмәттәшлекне үстерү – Россия тышкы сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренең берсе.

– Ил Президенты Владимир Путин күп тапкырлар Россиянең һәрвакыт мөселман дөньясы белән үзара хезмәттәшлекне киңәйтүчәгән һәм тирәнәйтүчәгән әйтте. Безнең илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда төп рольне «KazanForum» уйнарга тиеш, ул быелдан федераль дәрәҗәдә үткәрелә, – диде Россия вице-премьеры.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, дөньяның 65 иле, Россиянең 30дан артык төбәге вәкилләре, чит ил министрлары һәм дипломатлар форумда катнашу теләген белдергән инде.

– Халыкара җыенның эшлекле программасын тулыландыру буенча җитди эш башкарылды. Бүген 150дән артык эшлекле сессия узачагы билгеле. Аларда 750дән артык спикер катнашачак, – диде Рәис.

Чарага тагын бер ай чамасы гына вакыт калуга ишарәләп, оештыру эшләре белән бәрләттән, форум кунакларын каршы алуга да игътибарлырак булырга киңәш итте Рөстәм Миңнеханов. Аларга уңайлырак булсын өчен, җыен барышында Казанга килүче халыкара рейслар пассажирларына тизләтелгән чик контроле оештырылыр дип көтелә.

КЕШЕ ХЕЗМӘТЕ – ДӨНЬЯ АСЫЛЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фарит МӨХӘММӘТШИНның Яз һәм Хезмәт бәйрәме уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Яз һәм Хезмәт бәйрәме белән котлыйм!

Омтылышлары һәм һөнәри осталыгы күпмилләтле Ватаныбызның икътисадый һәм сәнәгый-технологик нигезен ныгытуга юнәлгән Хезмәт иясе эшчәнлеген ямьле майның беренче көнендә билгеләп үтү матур традициягә әйләнде. Яз җиту белән без табигатьнең уянуына, язгы җылы көннәр килүгә шатланабыз, уй-ниятләребез һәм максатларыбызның тормышка ашуына, киләчәкнең якты һәм тыныч булачагына ышанабыз.

Якташларыбызның берничә буынының иҗади хезмәте ярдәмендә Татарстан Республикасы икътисадый, фәнни һәм мәдәни куәткә, нык демократия традицияләренә, заманча норматив хокукый нигезгә ия булган көчле төбәккә әйләнде. Бүген без иң уңышлы үсә торган Россия Федерациясе субъектлары арасында булу белән хаклы рәвештә горурланабыз. Уңай социаль-икътисадый үзгәрешләр, иҗтимагый-сәяси тотрыклылык, милләтара һәм динара татулык безгә төп бурычны хәл итәргә – кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә. Бүгенге чорның авырлыкларына карамастан, республика үз үсешен дәвам итсен, ә илебез үз дәрәҗәсен ныгытсын өчен һәрвакыт алга омтылабыз. Көчебезгә ышанып, татарстанлыларга хас булган яшәү һәм эшләү теләгенә таянып, без бөтен сынауларны да уңышлы үтәрбез. Моңа минем шигем юк.

Татар халкында «Кеше хезмәте – дөнья асылы» дигән мәкаль бар. Туган илебезнең киләчәге хакына намуслы хезмәт – уртак өметләрнең, мул тормышның һәм тынычлыкның нигезе. Бәйрәмдә авыл хезмәтчәннәренә кояшлы матур көннәр һәм күтәренке рух телим – язгы кыр эшләренең кызган чагы бит. Республиканың икътисадый куәтенә нигез салган ветераннарга, үз урынында җаваплы һәм киеренке эшләүче барлык хезмәт ияләренә дә – олы рәхмәт сүзләре. Ышанам ки, Ватанга мәхәббәт, югары граждан җаваплылыгы, битараф булмау, социаль аңлылык һәм нәтиҗәле эшләү безнең киләчәк уңышларыбызның нигезе булачак.

Кадерле дуслар! Бәйрәм көнендә сезнең барыгызга да нык сәламәтлек телим. Кунакчыл җиребездә – тынычлык, ә йортларыгызда бәхет, иминлек һәм муллык булсын. Бәйрәм белән!

НӘСЕЛ ЮЛЫ

«Эшебез дә, гаиләбез дә – урман», – ди Мөхәммәтҗановлар.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Бүген һәркайсыбыз бу заводта төрле вазыйфа башкара. Бу эш безне берләштерә, туганлык җепләрен ныгыта. Безне шулай зурлаулары өчен бик зур рәхмәт! Заводыбыз, династиябез өчен зур горурлык хисе били. Бигрәк тә хәзер, шактый катлаулы чорда авиация тармагын күтәрүгә бар көчебезне куячакбыз, – ди.

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов фикеренчә, мондый фидакарь һөнәр ияләрен бүген аеруча да зурларга кирәк.

– Җаны-тәне белән үз һөнәренә тугры калган, ихлас кешеләр бу. Күпме еллар дәвамында илгә-көнгә, республикабыз халкына хезмәт итеп яши торган тырыш династияләр. Республиканың профсоюзлар берләшмәсе бу проектны республика күләмендә гамәлгә ашырып, бик дөрес эшләгән. Без андый кешеләребез белән горурланырга, шулар үрнәгендә бөтен җәмгыятьне тәрбияләргә тиеш. Илебез, республикабыз язмышы өчен андый кешеләр бик кирәк. Шушы династияләр аша кешенең рухи аңы, дөньяга, тормышка мөнәсәбәте, гаилә мөнәсәбәтләре – бөтен матур сыйфатлары чагыла, – ди Марат Әхмәтов. – Соңгы елларда җәмгыятьтә тормыш кыйммәтләре үзгәрә бара, кеше материальның азрак сыйфаты да какшап китте. Шуңа күрә менә шундый шәхесләрнең тормыш, яшәү рәвеше аша: «Менә җәмгыять шундый булырга тиеш», – дип аларны үрнәк итеп куясы иде. Бу проекта киләчәктә дә теләктәшлек һәм ярдәм күрсәтәчәкбез. Аны тагын да колачлырак итү һәм бөтен республика халкына таныту өчен тырышачакбыз.

Татарстан Профсоюзлар федерациясе рәисе Елена Кузьмичева исә, бу чара ел да үткәрелә торган матур традициягә әвереләчәк, дип ышандырды. «Республиканың барлык тармакларын да колачларга тырыштык. Үзләрендә озак еллар эшләүче куйган династияләрне барлап, олылап торган оешмаларга да рәхмәт әйтәсем килә», – диде ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Теләк булса, җае табыла

Бәйге

Татарстанда 5 майдан 30 майга кадәр физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен «Абилимпикс» төбәк чемпионаты узачак.

Быел катнашучылар саны, узган елгыдан 400гә артып, 1233 булган. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Татарстанның «Һөнәри белгечлекләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешманың генераль директоры Эмиль Гобәйдуллин сөйләде.

– Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр катнашындагы чаралар Россия Президенты Владимир Путин башлангычындагы «Россия – мөмкинлекләр иле» платформасы кысасында оештырыла. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та «Абилимпикс» хәрәкәтенә зур теләктәшлек күрсәтә. Республика чемпионатларга актив кушылды, 7 елда физик мөмкинлекләре чикле кешеләрнең һөнәри бәйгеләрендә 2 меңнән артык якташыбыз катнашты, – ди ул.

Һөнәри осталыкларын күрсәтүчеләрнең 414е – мәктәп укучысы, 425е – студентлар һәм 394е – белгечләр. Быел мәктәптә укучылар арасында катнашырга теләк белдерүчеләрнең артуын да әйттеләр. Аларның эшләренә бәяне республиканың 20 оешма-предприятиесе белгечләре бирачәк. Ярышлар 33 майданда, 91 төрле һөнәр буенча узачак. Алар аш-су әзерләү, чәчтараш, агач эшләре, рәсем-бизәк ясау, флористика, фотограф, компьютер программалары буенча да үз осталыкларын күрсәтәчәкләр.

Эмиль Гобәйдуллин әлеге ярышларның Казан, Чаллы, Түбән Кама, Арча, Лениногорск, Нурлат, Әлмәт, Болгар, Лаеш шәһәрләрендә узачагы турында да сөйләде.

– Быел әлеге ярышны Минзәлә мәктәп-интернатында да үткәрәчәкбез. Аларда беренче тапкыр уздырыла әле. Монда ата-ана назыннан мәхрүм калган физик мөмкинлекләре чикле балалар укый, – ди ул.

Сүз уңаеннан, шушы интернатта белем бирүче Гүзәл Шәйхетдинова белән аралашырга туры килде. Ул үзләрендә тәрбияләнүче сабыйларның уңганлыгын, эшне яратып башкаруларын әйтте.

– Балаларда эшкә өйрәнү теләге зур. Мондый бәйгеләр аларга көч өсти. Уз-үзләренә ышанычлары арта. Бездә тәрбияләнүчеләр иске газеталардан кәрзин үрә, сәйләннән бизәну әйберләре әзерли. Камыр эшләренә дә оста алар. Сыр да ясый беләләр. Кыскасы, уңганлыклары килеп күрегез, – ди ул.

Әлеге ярышта хәзерге вакытта хезмәт базарында нинди һөнәрләргә ихтыяҗ зур, шуларны сайлаганнар. «Иңин»нәрен сайлап алгач, алар 20–23 октябрьдә Мәскәүдә Татарстан данын яклаячак.

– Һәр ел саен «Абилимпикс» чемпионатында җиңүчеләргә бирелә торган төбәк һәм федераль ярдәм артып тора. Быел алар 100 мең сумнан башлап сертификатлар алачак. Ул акчаны өстәмә белем алырга, тернәкләндерү чарасына тотарга, һөнәри яктан үсәр өчен файдаланырга була. 1 нче урын алучы үзе дә, аны өйрәткән остазы да 150шәр мең сум акча алачак, – ди Эмиль Гобәйдуллин.

Бу ярышларның тагын бер файдалы ягы бар. Бирәдә эш бирүче – хезмәткәрле, ә һөнәрле кеше эшле булырга мөмкин. «Сетевая компания»нең генераль директор урынбасары Всеволод Семенюк әйтүенчә, алар да бирәдә хезмәткәрләр таба икән.

Ярышларда волонтерлар да катнаша. «Татарстан волонтерларының мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма директоры урынбасары Гүзәл Ганиева республикада волонтерлык эшенә үзе теләп кушылган 140 мең кеше барлыгын әйтте.

– Бу бәйге вакытында 500 волонтер ярдәм итәчәк. Сайлап алганнан соң, аларны укытачакбыз. Үзләрен яхшы яктан күрсәткән волонтерларны башка чараларга да чакырачакбыз, – ди ул.

Ә менә Александр Казаков, шушы бәйгедә катнашканнан соң, үз эшен башлап җибәргән. Аның хезмәт инклюзив агач ясау остаханәсе бар.

– 2019 елда бу чемпионатта катнаштым. Призер булып, 300 мең сум күләмендә грант оттым. Шул акчага эш башлар өчен кирәк-ярак сатып алдым. Остаханәмдә агачтан төрле эшләнмәләр ясыйбыз, – ди Александр. – Шулай ук бездә хәзер балаларны агач эшенә өйрәтә торган укулар да оештырыла. Иң мөһиме – теләк кирәк. Теләк бар икән, мөмкинлекләр дә табыла.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘЛМӘНДӘРНЕҢ КАЙТУЫ

ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ДАНЛЫКЛЫ ПЬЕСАСЫНА НИГЕЗЛӘНГӘН МУЛЬТФИЛЬМ ДӨНЬЯ КҮРӘЧӘК

almandar.tatar

Премьера

Тапкыр Әлмәндәр карт белән Әҗәл турында белмәгән кеше бармы икән? Һәрхәлдә, татарлар арасында. Тиздән бу тарихка яңа сулыш өрәчәкләр. «Татармультфильм» берләшмәсе пьеса сюжетын анимациягә күчергән. 10 майда халыкка легендар «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренә нигезләнгән мультфильм тәкъдим ителәчәк. Әлеге проект Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, «Татнефть» ярдәме белән булдырылды.

Хыялдан – чынбарлыкка

Камал театрының йөзек кашына әверелгән, 30 елдан артык сәхнәдән төшмәгән әлеге әсәргә алынулары, бер яктан, табигыйдер дә. Бер яктан, үсеп килүче буынны көр күңелле карт тарихы белән таныштыру, классикага якынайту булса, икенче яктан, шул әсәрне укыган, спектаклен күргән буынга аны кабат хәтердә яңарту өчен мөмкинлек тә.

«Татармультфильм» студиясе баш режиссеры Сергей Киатров әйтүенчә (ул – мультфильмның режиссеры да. – **Авт.**), Туфан Миңнуллинның нәкъ тә әлеге әсәренә алынулары юкка түгел. Бу иҗат коллективының авторга рәхмәт әйтүе дә икән.

– «Татармультфильм» берләшмәсе барлыкка килгән чорда, Туфан Миңнуллин безгә бик тә ярдәм итте, теләктәшлек күрсәтте. Аның әсәрләрен экранга чыгару турында күптәннән уйлана идек, шулай итеп аның төп әсәренә – «Әлдермештән Әлмәндәр»енә алынырга булдык, – ди режиссер.

МУЛЬТФИЛЬМ ТУРЫНДА – САННАРДА
- Мультфильмны барлыкка китерүдә 20 иллюстратор, 30лап аниматор катнашкан.
- Мультфильмда төп геройлардан алып җирдәге җәнлекләргә кадәр барлыгы 90 герой сурәтләнгән.
- Барлыгы 650 фон ясалган. Мультфильм 1126 күренештән тора. Хронометражы – 68 минут. Бу – музыкаль әсәр. Аның күп өлеше җырлардан гыйбарәт.
- Мультфильмны 1,5 ел әзерләгәннәр.
- Яшь чикләве – 6+.

Аның сүзләренә караганда, әлеге әсәр кинога күчерү өчен бик отышлы. Моннан тыш «Әлмәндәр» нигезендә гади, әмма гаять мөһим кыйммәтләр дә ята. Ул тәрбияви яктан да кадерле. «Биредә гаилә кыйммәтләре, тормышны ярату, халык зирәклеге – барысы да бар. Без, бер караганда, барысын да пьесадагыча һәм спектакльдәгечә иттек. Әмма, шул ук вакытта, пьесадагыча да, спектакльдәгечә дә түгел. Алар бер-берсен кабатламый», – диде режиссер.

Җанга якын тавышлар

Билгеле, спектакльне карап үскән буынга Равил Шәрәфиев уйнаган Әҗәл белән Шәүкәт Биктимеровның Әлмәндәр карты кадерле һәм якын. Тамашаны хәтердә генә яңартсак та, колакта аларның тавышлары яңгырап куя. «Әлдермештән Әлмәндәр» мультфильмында да җанга якын тавышлар ишетеләчәк.

– Төп рольне – 1550 нче номерлы агентны, ягъни Әҗәлне Равил Шәрәфиев тавышландырды. Без моның белән бик горурланабыз. Ул спектакльдә бу ролен 30 елдан артык башкарды, – ди Сергей Киатров. – Оста шәхес белән эшләү безгә дә кызык һәм рәхәт булды. Ул – чынлап та, уникаль кеше. Актер Эмиль Талипов – Әлмәндәр картка тавыш бирүчебез. Тавышландыру вакытында, микрофон каршында Эмиль Әлмәндәр карт образына шулкадәр тырышып керә иде. Илнур Закиров хатын-кыз рольләреннән кала барлык персонажларга үз тавышын бүләк итте. Кирәк икән – малай, кирәк икән – бабай да булды ул. Әлмәндәр дустын – Ястәгнәйне исә мин тавышландырдым.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«Россия лидерлары»

РАФАЭЛЬ ВӘЛИЕВ: *«Рөстәм Миңнеханов минем остазым иде»*

Һичшиксез катнашырга һәм үзеңне сынарга. «Россия лидерлары» конкурсы турында Рафаэль Вәлиев шулай ди. Белми әйтмәс: үзе дә былтыр җиңүче булды бит ул. Рафаэль Вәлиев хәзерге вакытта «Береке-Банк»та (Казахстан) технологияләрне үстерү буенча өлкән идарәче директор вазыйфасын башкара. Бәйгенең әһәмияте турында аннан сораштык.

«Россия лидерлары» бәйгесендә тәүге тапкыр катнашып, җиңүгә ирешә ул. Дөрес, беренче коймак төерле булган кебек үк, яхшы нәтиҗәгә өметләнми. Әмма тырышлык үзенекен итә шул. Сүз уңаеннан, былтыр бәйгенең суперфиналында республикадан җиде кеше катнашкан, шуларның өчесе җиңде. Аңлашылганча, Рафаэль дә – шулар арасында.

– Конкурс – үзеңне һөнәри сәләтләреңне, мөмкинлекләреңне тикшерү, сынау, яңа кызыклы шәхесләр белән танышу һәм үсеш өчен шәп мәйданчык, – ди әңгәмәдәшебез. – Бәйгенең суперфиналистлары белем алу өчен грант ота. Илнең теләсә кайсы югары уку йортында укырга мөмкин, димәк. Бу бит инде – шәп мөмкинлек! Һичшиксез катнашырга һәм үзеңне сынарга тәкъдим итәм. Конкурсны оештыру дәрәҗәсе бик югары. Биремнәр дә кызыклы, чынбарлыкка якын.

Рафаэль Вәлиев искәрткәнчә, әлеге бәйгегә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та һәрчак хәерхаһлы. «Ул бик зур ярдәм күрсәтә. Конкурсның остазы да булып санала. Рөстәм Миңнеханов минем дә остазым иде. Ул безне, башка җиңүчеләр белән беррәттән, кадрлар резервын әзерләү программасына чакырды», – дип сөйләде Рафаэль Вәлиев.

Җиңүдән тыш, конкурс тагын нәрсә бирә соң?

– Искиткеч сыйфатларга ия кешеләр белән берләшәсең, үзеңә карата таләпчәнлекне арттырасың. Бу инде яңа үрләргә этәрә, – ди Рафаэль. – Конкурста катнашу нәтиҗәсендә мин идарәче сыйфатларын камилләштердем.

БӘЙГЕ ТУРЫНДА
- «Россия лидерлары» идарәчеләр конкурсы бишенче мәртәбә оештырыла.
- Гаризалар тапшыру 14 майга кадәр дәвам итә. Конкурста катнашу бушлай. Тулырак мәгълүматны конкурсның сайтыннан белергә мөмкин (лидерыроссии.рф).
- Конкурсны Россия Президенты Владимир Путин йөкләмәсе буенча «Россия – мөмкинлекләр иле» платформасы үткәрә.
- Сәләтле, идарә итү осталыгы булган җитәкчеләрне ачыклау, үстерү һәм аларга ярдәм итү максатын күздә тота.
- Бишенче сезонда катнашу өчен хәзерге вакытта Россиянең барлык субъектларыннан һәм 70тән артык чит илдән 60 меңнән артык гариза кабул ителгән.

АЛМАН ИЛЕНДӘ – ТАТАР КАБЕРЛЕГЕ

Тарих

Германиянең Вюнсдорф шәһәре янындагы Церенсдорф авылында (ул авыл хәзер юк инде) Беренче Бөтендөнья сугышы әсирләренең мөселман татар зираты турында без әледән-әле ишеткәләп торабыз. Бүген Татарстан һәм Германия галимнәре бу татар зиратын тулысынча тәртипкә китерергә ниятле. Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары Марат ГЫЙБАТДИНОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Марат Мингалиевич, чит илләрдә ятып калган мөселманнарның каберләрен беренче тапкыр гына барлавыгыз түгел дип беләм. Германиядәге бу каберлек ничек, кайчан барлыкка килгән? Язмышы ничек булган?

– Без моннан берничә ел элек Польшада да, Германиядә дә татар әсирләре күмелгән урыннарны барлап, архив эшләре белән шөгыльләнергә килешүләр төзеп кайткан идек. Шул вакытта татарлар күмелгән каберләрнең саны 20–30ар меңгә җиткәнен чамаладык. Чөнки милләттәшләребез хәрби хезмәтләргә күп алынган, сугышларда бик актив катнашкан. Вюнсдорф лагере янындагы мөселман зиратында 1100 тирәсе кабер исәпләнә. Ул 1915 елның апрелендә барлыкка килә. Анда беренчеләрдән булып Әхмәтлатыйф Әхмәтҗанов, Хәбибулла Фәйзуллин җирләнә. Иң соңгы булып, 1920 елның 19 декабрендә җирләнгәне – Хәлиулла Сәйфуллин. Зираттагы каберләрнең 400 тирәсе генә Россия империясендәге мөселманнарга карый. Күпчелеге татарларныкы дип фаразлана. Ә калганнары – Англия гаскәрендә хезмәт иткән гарәпләр, индуслар, башка мөселман халыкларыныкы. Белгәнебезчә, Германия хөкүмәте әсирләргә яхшы мөнәсәбәттә була, намаз укырга, гаетләр уздырырга, хәләл ризыклар әзерләргә мөмкинлекләр тудыра. Яралардан, төрле авырулардан үлеп китүчеләрне җир куенына мөселманча индергәннәр. Сугыш тәмамлангач, Британия империясе үз гаскәрләрендә хезмәт итүчеләрнең каберләрен тәртипкә китерә. Әйтергә кирәк, анда хәзер дә тәртип: таштан һәйкәлләр куелган, каберләр чәчәккә күмелеп утыра. Шунда ук мәгълүматлар язылган китап та бар. Кем, кайдан килгән, ничек үлгән – барысы турында да белергә була. Зиратның Россия мөселманнары җирләнгән өлешен Икенче Бөтендөнья сугышына кадәр Берлинда яшәүче дин кардәшләре карап тота. Аннан соң бу урын совет гаскәренең хәрби атышлар урынына әйләндерелә, чит-ятларга керү тыелган була. Зират өсте урман эчендәге бер алан булып кала.

Хәзер инде агач кабер билгеләре күптән черегән, зират урыны икәнен хәбәр итеп, гомуми зур таш кына тора. Соңгы тапкыр барганда шул күзгә чалынды: инде монда кешеләр ял итәргә килә башлаганнар. Дөрес, ул урын койма белән тотылган, әмма каберләре беленеп тормагач, зират икәнен белеп бетермиләрдер, күрәсең. «Татар өлеше»ндә берничә индус та җирләнгән булган. Британиялеләр аларга да таш куйган. Безнекеләр шул килеш калган. 2000 елларда Татарстан Президенты ярдәме белән зиратны карарга акча да бүлеп бирелгән иде. Каберлек өлешчә ремонтланды. Әмма ул вакытта кайда кем ятканын белеп булмады, чөнки чыганаклар җитмәде. Шул вакытта зур бер таш тергезелде. Ул да таушала башлаган инде.

:: Бу эшкә кабат тотыну нинди нәтиҗәләр бирде?

– 2022 елда Татарстан һәм Германия галимнәренең тырышлыгы нәтиҗәсендә 409 кабердә кем ятканын ачыклый алдык. 2000 елда немецлар, каберләрнең кемнеке икәнен ачыклап булмас, чөнки карталар да, документлар да сакланмаган, дигәннәр иде. Ләкин без, эзләнә торгач, Британия архивында зиратның картасын таба алдык. Германиядәге тарихчылар белән бергә каберлекнең электрон картасы ясалды. Сакланып калган фотолар белән чагыштырып карадык. Барысы да туры килә. Монда әсирләр теләсә ничек җирләнмәгән. Каберләр рәт-рәт урнаштырылган. Хәрби зират булгач, тәртип бигрәк тә нык булгандыр инде. Шулай итеп, кемнең кайда җирләнгәнен төгәл ачыклый алдык. Хәзер безнең максат – зиратны элекке кыяфәтенә кайтарып, һәр кабергә исем-фамилия язып, таш куярга.

Беренче эш итеп, Германиядә хәрби зиратларга хезмәт күрсәтүче комиссиягә хат яздык. Аларның планнарын беләсебез килә. Аннан килеп, зиратны төзекләндерергә керер өчен рөхсәт тә кирәк бит әле. Икенче чиратта исә финанс мәсьәләсен хәл итәргә кирәк булыр. Моңа кадәр эшләгән гамәлләр нигездә архивка бәйле иде. Шуңа күрә күп акча кирәк булмады. Ә менә зиратны торгызу өчен күп чыгымнар кирәк булачак. Хәзерге сәясәт катлаулы булуга карамастан, мин бу эшне ахырына кадәр очлап чыгып булыр дип ышанам. Хәрби каберлекләр турында ике ил арасында килешү дә бар бит. Әлеге документ нигезендә ике якның да чит илдә ятып калган сугышчылары, әсирләре җирләнгән урыннар бертигез каралырга тиеш. Германиядә әсирләр яткан зиратларны төзекләндерү планы бар. Без бик күп каберлекләрне карап йөрдек. Бигрәк тә Икенче Бөтендөнья сугышына кагылышлы булганнарын. Күбесе тәртиптә. Планга кертелә калса, бәлки, алар татар зиратын торгызу эшләрен дә финанслый алырлар. Тик, ничек кенә булса да, безнең яктан да акча кирәк булыр дип уйлыйм. Вактөяк эшләр дә килеп чыгарга бик мөмкин. Җирләнгән кешеләрнең исем-фамилияләре билгеле бер үлчәмдәге агачларга язылган булган. Минемчә, хәзер шул ук зурлыкта таш билгеләр куярга кирәк.

:: Германиядә татар зиратын төзекләндерүне планга кертү мөмкин эшме?

– Тизләтер өчен Татарстан ягыннан кызыксыну кирәк дип уйлыйм. Менә без институт исеменнән хат яздык. Бәлки, югарырак даирәләрдән, Рәис исеменнән кирәктер… Икенче этап итеп, интерактив карта ясарга уйлыйбыз. Монысы зиратны һәркем карый алсын өчен кирәк.

:: Һәркем карый алсын дигәннән, ничек уйлыйсыз, кызыксынучылар булырмы икән?

– Ничек кенә әле! Бу безнең барыбыз өчен дә кирәк. Беренчедән, бабаларыбыз яткан урынны белергә тиешбез. Безнең чит илдәге зиратлар белән шөгыльләнгәнебезне белеп, бик күп кешеләрдән, үз бабасы, тулганнары яткан урынны табып булмас микән дигән сораулар булды.

М. Гыйбатдинов

Зираттагы «Татар ташы»ның бүгенге халәте.

Икенчедән, без бабаларыбызның «мәңгелек йорт»ларын кадер-хөрмәттә тотарга, исемнәрен онытмаска тиешбез. Ахыр чиктә алар бит чит җирләргә үз теләкләре белән китмәгән. Хәрби хезмәткә алынып, дәүләт мәнфәгатьләрен якларга барган. Өченчедән, без бу гамәлебез белән татарларның Россия мәнфәгатен яклауда нинди өлеш керткәннәрен тагын бер кат күрсәтә алабыз.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

27 апрель, 2023 ел № 15/103 Казан ш.

20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлыгына теркәлгән кандидатларга төбәк (республика) дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган бушлай эфир вакытын бүлү графигы турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 61 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, **карар бирә**:

1. 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлыгына теркәлгән кандидатларга төбәк (республика) дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган бушлай эфир вакытын бүлү графигын (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу карарны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә.
3. Бу карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Үзәк
сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк
сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
27 апрель, 2023 ел, № 15/103 карарына кушымта

20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлыгына теркәлгән кандидатларга төбәк (республика) дәүләт телерадио оешмалары тарафыннан бирелә торган бушлай эфир вакытын бүлү графигы

				ВГТРК ФГУП филиалы «Татарстан» ГТРК, «Россия 1» телеканалы	ВГТРК ФГУП филиалы «Татарстан» ГТРК, «Россия 24» телеканалы	ВГТРК ФГУП филиалы «Татарстан» ГТРК, «Радио России» радиоканалы	«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ, «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» телеканалы	«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ, «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалы	«ТАТМЕДИА» АҖ «Кама-ТВ Набережные Челны»	«ТАТМЕДИА» АҖ «Күңел радиосы» (Радио Настроение)	«ТАТМЕДИА» АҖ «Чаллы - ТВ телекомпаниясе» (Телекомпания «Челны - ТВ»)
Бер мандатлы сайлау округы атамасы	Фамилиясе	Исеме	Атасының исеме	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты	Сайлау алды агитациясе материалларының (роликларның) эфирга чыгу көне, вакыты
20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы	Быков	Александр	Владимирович	16.05.2023 17:00-23:00	24.05.2023 17:00-23:00	11.05.2023 17:00-23:00	24.05.2023 17:50 № 3	24.05.2023 11:15 № 2	23.05.2023 20:25 № 3	22.05.2023 18:30 № 5	22.05.2023 18:20 № 4
	Вахитов	Адель	Раил улы	11.05.2023 11:00-17:00	17.05.2023 17:00-23:00	18.05.2023 05:00-11:00	24.05.2023 17:50 № 1	17.05.2023 11:15 № 2	23.05.2023 20:25 № 2	22.05.2023 18:30 № 4	22.05.2023 18:20 № 3
	Зыятдинов	Ирек	Фәрит улы	25.05.2023 11:00-17:00	24.05.2023 17:00-23:00	25.05.2023 17:00-23:00	17.05.2023 17:50 № 3	24.05.2023 11:15 № 3	23.05.2023 20:25 № 6	22.05.2023 18:30 № 1	22.05.2023 18:20 № 2
	Мухина	Татьяна	Александровна	18.05.2023 05:00-11:00	24.05.2023 05:00-11:00	18.05.2023 05:00-11:00	17.05.2023 17:50 № 1	24.05.2023 11:15 № 1	23.05.2023 20:25 № 1	22.05.2023 18:30 № 6	22.05.2023 18:20 № 1
	Нигъмәтуллин	Руслан	Рәвис улы	18.05.2023 05:00-11:00	17.05.2023 17:00-23:00	25.05.2023 17:00-23:00	24.05.2023 17:50 № 2	17.05.2023 11:15 № 1	23.05.2023 20:25 № 5	22.05.2023 18:30 № 3	22.05.2023 18:20 № 6
	Сираев	Илнар	Рәшит улы	25.05.2023 11:00-17:00	24.05.2023 05:00-11:00	25.05.2023 11:00-17:00	17.05.2023 17:50 № 2	17.05.2023 11:15 № 3	23.05.2023 20:25 № 4	22.05.2023 18:30 № 2	22.05.2023 18:20 № 5

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Булган хәлләр

САЛАВАТ БУЛМЫЙ!

90 нчы еллар. «Маркетинг» дигән сүзне күпләр әле ишетеп тә белми. Ә Алмаз Хәмзин гениаль маркетинг адымы уйлап чыгара. Төрле коммерцияле тамашалар, «солянка» концертлар популярлашып киткән чор бу. Алмаз абый да шундыйларны оештыргалаштыргалый. Әмма билетны ничек сатарга? Залны ничек тутырырга? Хәмзин аптырап тормаган, афишага зу-ур итеп «Салават» дип язып куйган да аста кечкенә генә хәрефләр белән «булмый» дип өстәгән. Химиклар мәдәният сарае яныннан трамвай белән узган казанлыларга афишада «Салават» сүзе кычкырып тора. Якынрак килсәң, «Салават булмый» дигән икән! Маркетинг дәреслегенә кертү өчен менә дигән мисал булган бу.

АЗ-МАЗ ХӘМЗИН

Әлеге дә баягы Алмаз Хәмзин. Ни кызык, ул якын-тирәдәгеләрне генә түгел, үз-үзен дә бераз чеметеп алырга ярата. Алмаз абый белән берәр мәҗлестә, йә булмаса берәр сәфәрдә булган кеше белә: аның баяны үзеннән калмый. Һәрвакыт машинасында йөри. Тота да уйнап җибәрә ул аны, ялынганны көтми. Аннан килеп җырлый башлый, биергә дә күп сорамый. Арып китсә, берәр мәзәк сөйләп күңелне күтәрә. Шуңа күрә аны еш кына «человек-оркестр» дип йөртәләр. Әле язучы икәнен әйтергә онытканбыз, китаплар авторы, җырлар иҗатчысы һ.б. Шуңа һәр эшне әз-әзләп башкарганга күрә Алмаз абый үзен Аз-маз Хәмзин дип йөртә башлаган.

СӘЙДӘ АППАКОВАНЫҢ «КУРКЫНЫЧ» ВӘГАЗЕ

Бу хәлне безгә дини мәҗлесләр алып баручы Марсель Әхмәдуллин сөйләде. Марсельне мәктәптә Сәйдә абыстай Аппакова укыткан. Берзаман укучыларга дини темага вәгазь сөйләгән ул. Җәннәт белән җәһәннәмне дә аңлаткан. Икенче көнне бер баланың әнисе директор янына керә, «Минем балам җәһәннәм турында сөйләгәннәрне ишетеп бик курыккан», – дип шелтә белдерә ул. Ана кеше өметләнүенчә, директор Сәйдә Аппакованы үзенең кабинетына чакырып, «выговор» бирәчәк. Тик өметләр акланмый. Директор укытучы ягын ала. «Безгә мондый куркак балалар кирәкми», – дип, ана кешене кабинетыннан озатып җибәрә.

Хи-хикәя

ПЕЛӘШ ҺӘМ КАРА ЧӘЧЛЕ

(КЛАССИК БУЕНЧА ДИЯРЛЕК)

Казан урамында пеләш башлы белән кара чәчле очрашты. Кара чәчлесенең хәзер генә рестораннан чыгып килеше булып, аның пешкән чиягә охшаган кабарынкы иреннәре майланган, үзеннән кыйммәтле хушбуй исе аңкып тора. Пеләш башлысы яңа гына троллейбустан төшкән иде. Аннан тир, кәгазь, контора келәе исләре килә.

– Сәмигулла! – дип кычкырып җибәрде кара чәчлесе. – Синме соң бу, дускай?

– Әйе! – дип гаҗәпләнде пеләш башлысы. – Мирхәйдәр! Кайлардан килеп чыктың син?

Дуслар, кочаклашып, бер-берсенең аркаларына суккалап алдылар.

– Менә бу очрашу, дус! – диде пеләш башлысы, шатланып. – Көтмәгән идем! Бер дә үзгәрмәгәнсең! Шундый ук чибәр, шундый ук көяз! Йә, эшләр ничек? Кайда эшлисең? Өйләндеңме? Күрәсең, мин өйләндем инде... Менә бу – хатыным Люция. Ә бу – малаем Рево, өченче класста укый. Люция, бу – минем балачак дустым! Мәктәптә бергә укыдык!

Люция җиңелчә генә башын иеп алды. Рево бераз уйланып торды да җиңелчә генә ым кагып куйды.

– Мәктәптә бергә укыдык!.. – дип дәвам итте пеләш башлысы. – Хәтерлисеңме, математикадан бик азаплана идең син. Сөләйман абый сиңа «өчле»не дә, аптыраганнан гына сөям, кәҗәкәй, дип куя иде, ә!.. Аның каравы бик үҗәт идең син! Тәки ырып-ерып чыктың мәктәпне!.. Их, ничек тиз үтә гомер! Кайчандыр без дә бала-чага идек. Курыкма, Рево! Абый кешегә якынрак кил! Ә менә бу – минем хатыным Люция...

Рево бераз уйланып торды да җиңе белән борынын сөртеп алды.

– Сөйлә, ничек яшисең, дус? – дип сорады кара чәчлесе, дустына сокланып карап. – Кайда эшлисең?

– Эшләр бара әкренләп. Бер конторада өлкән инженер булып эшлим инде мин, дускай! Оклад зур түгел түгелен дә, ләкин ярый, зарланмыйм. Җәй көннәрендә тал чыбыкларыннан кәрҗиннәр үрәм. Бакчачылар теттереп ала! Кышын төннәрен кибет сакларга урнашам. Бикләнәсең дә черем итеп ятасың! Биш елдан ике бүлмәле квартира вәгъдә итәләр! Хәзергә каенанада яшибез. Ә үзең ничек? Син дә зур кешедер инде, ә?

– Әлбәттә, гади түгел! Берләшмә җитәкчесе мин, дускай!

Кинәт пеләш башлының төсе агарынды, йөзе, таштай катып, гәүдәсе кечерәеп калды, аннары ничектер елмайгандай булды. Хатыны, әле иренә, әле аның яшьлек дустына карап, өнсез калды. Рево әтисенең артына ук яшеренде.

– Молодец сез! Мин бик шат. Үзегез яшьлек дустым дияргә була... ә үзегез шундый зур кеше булгансыз!..

– Ярар сана! – дип кашын җыерды кара чәчлесе. – Син нигә шулай әле? Кирәкми! Без синең белән балачак дуслар бит!

– Ташлагыз ла, зинһар! Сез нәрсә... – дип көлде пеләш башлысы. – Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Таныш булыгыз: бу – минем хатыным Люция... Монысы – малаем, Рево ягъни...

– Мин шатмын, дус. Сезгә кайсы якка? – дип сорады кара чәчлесе. – Илтеп куям. Йә минем дачага барыйк? Иркенләп сөйләшеп, балачакны искә алып утырырбыз! Йә булмаса, өйгә кайтыйк! Анда иркен минем! Өчебезгә дүрт бүлмәле квартира!

– Юк! Юк! Кая ул?! – дип кул селтәде пеләш башлысы. – Әле безнең кибетләрдә йөрисебез бар. Гафу итегез, мөмкин булса, әлбәттә... Сез кайсы берләшмәдә эшлисез?

– Математик анализ белән шөгыльләнүче фәнни берләшмәдә! – диде кара чәчлесе.

Һәм ул шалт итеп «Вольво»сының ишеген япты да, чәче кебек үк чем-кара машинасы, артыннан зәңгәр төтен калдырып, урыныннан кузгалып китте.

Пеләш башлы дусты, хатыны Люция һәм малайлары Рево, ни әйтергә дә белмичә, машина артыннан карап калдылар. Бераздан, айнып, «Комиссионные товары» кибетенә таба юнәлделәр...

Әхәт САФИУЛЛИН

Фотошок

Бу рәсемдә – мәсәлнең башы. Мәсәлнең ахырын беләсегез килсә, әлеге рәсемне 180 градуска әйләндереп карагыз.

Түти, нихәл?

– Ничек хәлләрең?
– Ничек дип әйтим... Юлны йөгереп чыгучы кара мәчеләр миннән бөтенләй өметләрен өзде.

* * *

– Минем яңа эшем маникюрыма туры килми, инде нишләргә?

* * *

– Бу яз көне спортзалны алдадым.
– Ничек?
– Акчасын түләдем, ә үзем йөрмим.

* * *

Ирем эш буенча ике атнага китеп барды. Хәзер ир-ат эше минем өстә. Диванда хоккей карап ятам.

* * *

Күрәсең, балачакта качышлы уйнаганда мин шундый шәп итеп качканмын, 40 яшемдә дә үземне таба алмыйм.

* * *

– Миннән «Ничек хәлләрең?» дип сорагач, мин шатланып куям. Димәк, тышкы кыяфәтем буенча гына әле аңлый алмыйлар.

* * *

– Сезнең Лилия кияүгә чыктымы соң әле?
– Чыга әкренләп.

* * *

– Кәефем гел үзгәреп тора, миңа нишләргә, доктор?
– Кәефегезне гел төшенке тотыгыз, уйнакламасын.

* * *

Язгы депрессия инде туйдырды. Әйдә, җәйгесен башлыйбыз.

Фотофакт

Төмән өлкәсеннән рәссам Полина Филатова иҗат өчен үзенчәлекле урын тапкан. Иске тукталышларның эчләрен бизи ул. Автобус көткәндә мондый тукталыш эченә керәсе генә килеп тора. Афәрин, Полина! Болай да мич коймагы ашыйсы килеп тора иде, бу фотоны күргәч, бигрәк тә.

Әз-мәз мәзәк

Медицина хәзер бик алга китте безнең кечкенә генә шәһәребездән.

* * *

– Ләйсән, без ике атнага Төркиягә җыенабыз. Песиебезне сездә калдырып торыйк әле?
– Соң сез әле соңгы баруыгыздан да песиегезне алып китмәдегез бит.

* * *

Егет белән кыз бер-берсен ярата икән, моның турыда бөтен дөньяга кычкырырга кирәкми. Әмма бергә төшкән фото да бик матур шул...

* * *

Дөньяның бөтен авырлыкларын җиңәсең, бөтен проблемаларны чишәсең, үзеңне батыр дип хис итәсең һәм кибеттә кулыңа ачып булмый торган пакет эләгә.

* * *

Берәр кешегә шалтыратсаң, «телефонны Марат бирде» дип әйт. Марат исемле танышы булмаган кеше юк бу дөньяда.

КЕР ЮУ ТӘРТИБЕ

Кер юарга – 60 минут.
Керне киптергечкә эләргә – 10 минут.
Киптән керне төреп шкафка куярга – 7 көн.

vk.com

Танышу һәм кавышу

Мин оекбаш сыман. Парымны таба алмыйм.

* * *

– Ә мин сине ничек танырмын соң?
– Мине күргәч, «ул булмаса гына ярар иде» дип уйлап куярсың, менә шул мин булырмын.

* * *

Күзлекле кызларга рәхмәтле бул. Алар, беләсең килсә, сине күрер өчен күзлек сатып алган.

* * *

Әгәр дә синең йөргән кызың хайваннар ярата икән, сиңа нәрсә дип әйтергә дә белмим инде...

* * *

Мин егетләр өчен дип бизәнмим. Мин зур тәрәзәле кибетләр яныннан узганда үземә карар өчен бизәнәм.

* * *

– Танышабызмы? Мин эчмим, тартмыйм. Кичке унда йокларга ятам. Иртәнге унда торам. Тәртип бозмыйм. Әмма төрмәдән чыксам, ничек булыр – анысы билгесез.

* * *

Бу яшьтә ямьсез фамилияле егет белән очрашып йөрү шактый куркыныч.

* * *

Әгәр дә кызның социаль челтәрендә яңа фотолар юк икән, димәк, ул үз тиңен тапкан. Йә булмаса, баш күтәрми эшли.

* * *

– Миңа мускуллы егетләр кирәкми. Алар минем белән төнге бердә табаны кырып, кызган бәрәңге ашамаячак.

Кирле-мырлы уйлар

Еллар узгач, акыл керми. Еллар узды, ә акыл кермәде, дигән акыллы фикер генә керә.

* * *

Бүгенге дөньяда син бары тик бер генә нәрсәгә әзер булырга тиеш: бөтен нәрсәгә.

* * *

Бүген эшлисе эшне иртәгәгә калдырма. Берсекөнгә калдыр. Ике көнең буш булыр.

* * *

Минем бөтен бюджетым «кирәге бар иде» һәм «дөньяда бер генә яшибез» дигән пунктлар арасына сыеша.

* * *

Ябыгу өчен дигән чәйне торт белән эчсәң, нәрсә булыр икән?

* * *

Чәчтарашка «иртәгә 10 ел утырган ирем төрмәдән чыга, аның өчен матур буласым килә» дисәгез, чәчегезне, һичшиксез, матур алачак.

* * *

Әгәр дә сөт тиз әчи икән, без аны шундук ташлыйбыз. Әгәр дә сөт бик озак әчеми тора икән, без аны «мондый сөт буламыни» дип ташлыйбыз.

Бик матур песи баласы алган идек. Әмма иремнең аллергия. Бәлки, берәрегезгә кирәктер? Буе – 185 см. Эчми-тартмый. Машина йөртүче булып эшли.

ҖӘЙ КӨНЕ

ЭШТӘ ӘЙТЕРГӘ ЯРАКЛЫ ӘЗЕР ШАБЛОННАР

✓ Мин иртәгәдән җәйге ялга чыгам, ялдан соң искә төшер әле.
✓ Мин бүген ялдан соң беренче көнем эшлим, башым эшләми.
✓ Әйдә Сабантуйлардан соң кайтыйк әле бу мәсьәләгә!
✓ Бүген җомга көн бит, кыска көн, төшке аштан соң авылга кайтып китәсе.
✓ Мин өч ел җәйге ялсыз эшлим, тимә миңа!

vk.com

Мач әйткән!

Александр АБДУЛОВ, актёр

Тормышның озынлыгы сиңа өстән бирелгән. Ә киңлеген үзең хәл итәсең.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Газетаның киләсе саны 3 майда чыга.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 261

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+